«.

КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 25 ноябрь г.Казань № 1516

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының салым чыгымнары исемлеген һәм салым чыгымнарын бәяләүне формалаштыру тәртибен раслау турында» 2019 ел, 13 сентябрь, 831 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының салым чыгымнары исемлеген һәм салым чыгымнарын бәяләүне формалаштыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының салым чыгымнары исемлеген һәм салым чыгымнарын бәяләүне формалаштыру тәртибен раслау турында» 2019 ел, 13 сентябрь, 831 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының салым чыгымнары исемлеген һәм салым чыгымнарын бәяләүне формалаштыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта «, Татарстан Республикасы дәүләт программаларының структур элементлары» сүзләрен төшереп калдырырга;

5 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарына» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

16 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Татарстан Республикасы салым чыгымнарының максатчанлыгы критерийлары булып түбәндәгеләр тора:

Татарстан Республикасы салым чыгымнарының Татарстан Республикасы дәүләт программалары максатларына һәм (яисә) Татарстан Республикасы дәүләт программаларына кермәгән Татарстан Республикасы социаль-икътисадый сәясәте максатларына туры килүе;

бирелгән ташламаларга түләүчеләр тарафыннан ташламаларга хокуктан файдаланучы түләүчеләр санының һәм ташламалар куллануга потенциаль хокукка ия

түләүчеләр санының нисбәте, яки биш еллык вакыт эчендә түләүчеләрнең гомуми саны белән характерлана торган ихтыяҗ булу.

Кирәк булганда, Татарстан Республикасы салым чыгымнары кураторлары тарафыннан түләүчеләргә ташламалар бирү максатчанлыгының башка критерийлары билгеләнергә мөмкин.

Татарстан Республикасы салым чыгымнары кураторы тарафыннан бирелгән ташламалар түләүчеләр тарафыннан таләп ителүен бәяләүне уздыру максатларында ташлама таләп ителгән дип танылa торган әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән нисбәтнең минималь мәгънәсе билгеләнергә мөмкин.

Татарстан Республикасы салым чыгымнарының әлеге пунктта күрсәтелгән критерийларның берсенә генә булса да туры килмәсә, Татарстан Республикасы салым чыгымы кураторына Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына түләүчеләр өчен ташламаларны саклау (аныклау, юкка чыгару) турында тәкъдимнәр кертергә кирәк.»;

түбәндәге эчтәлекле 19[1] пункт өстәргә:

«19[1]. Татарстан Республикасы салым чыгымнары кураторы кирәк булганда Татарстан Республикасы салым чыгымнарының бюджет нәтиҗәлелеген бәяләүнең өстәмә критерийлары билгеләнергә мөмкин.»;

түбәндәге эчтәлекле 20[1] пункт өстәргә:

«20[1]. Татарстан Республикасы салым чыгымнарының нәтиҗәлелеген бәяләүне Татарстан Республикасының техник салым чыгымнарына карата үткәрмәскә рөхсәт ителә.»;

әлеге Тәртипкә кушымтага түбәндәге эчтәлекле 20[1] пункт өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «20[1]. | Салымнар түләүчеләрнең гомуми саны (берәмлек) | Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе мәгълүматлары». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин